«Кыйссаи Сәкам»*

1. Хуран шаһы кызына Сәкамның гашыйк булганы

1. Бар ирди бер падишаһ — Җиһаншаһ аты,
Үзендә күб ирди малы-мөлкәте.
2. Йәнә күб ирди аның илләри,
Хисаб кыйлгусыз ирди аның малларый.
3. Аның бер кызый бар ирди сыйфат кыйлгусыз,
Йәнә күркы Тәңридин үзгәгә билгүсез.
4. Хәрәмләб, бизәнеб, йасануб ай тик кубыр,
Каумир аңа булдый гашыйк — бик, шаһ, вәзир.
5. Кем ирсә теләди — аный бирмәди,
Ничә мал килтүрди, аный алмадый.
6. Бар ирди ул вакытда күклүк йегет,
Атый Сәкам ирди әйтәйем ишет.
7. Нагяһ Сәкам ул кызга гашыйк булдый,
Йәлавыч йибәрүбән кызны кылдый.
8. Йәлавыч йибәрмешсән кызыйм кылгалый,
Кабул күрдүм мин сиңа кызыйм биргәли.
9. Вәләкин җиһанда син ул дәлил пәһлеван,
Бу йирдин баргыйл Мәккәгә рәүван.
10. Биш нәрсә әйәйин — алыйб килтүр миңа,
Милкемнең йарумый, кызыйм һәм сиңа.
11. Син сорар булсаң бу эшләрни миңа,
Җавабыны әйтәйем, кил, мин сиңа.
12. Анча мин сордум кайу биш нәрсә,
Әйүб бир миңа син җавабыйн кисә.
13. Әүвәл кем, ул Галинең кис башыйн,
Икенчи зөлфокар, өчүнчи Канбар эшин.
14. Түртенчи Делдүл намдар атыйн,
Бишенчи пәһлеван Мәликнең гөрзесин.
15. Бу бишне бетүрүб килтүрсәң эшим,
Бирүрмен сиңа ул нигяриңдин кызыйм.
16. Ул сәгать бу Сәкам җуан,
Мәккәгә атландый ушал пәһлеван.

2. Сәкамнең Мәккәгә килгәне һәм анда орышлары

17. Мәккәгә тигди ул кач көндән кизин,
Кирәкмәздир миңа Галидин изин.
18. Шәһәргә керди ул чаулан илә,
Гали кайдадур — тиб, айгыл һалә.
19. Күрәйем мин имди Галинең эшин,
Хуран мәликкә илтәйен башыйн.

* М. Әхмәтҗановның «Кыйссаи Сәкам» дастаны турындагы махсус мәкаләсе журналның үткән санында басылган иде (Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2006. – № 2. – Б. 173-179).

20. Гали өчүн килдүм бу йиргә үзүм,
Мәйданга чыксун әйәйем сүзүм.
21. Галигә барыйбән хәбәр кыйлдыйлар,
Сәкамнең килмешин камугъ белдиләр.
22. Галинең катында ун йарый бар ирди,
Уларның олугы — ул Халид ирди.
23. Халид кубдый, әйтүр, дәстүр бир миңа,
Башыйн тәрик кисән киләйен сиңа.
24. Халид бардый, керди мәйданга ишет,
Ач арыслан мингизлик күрәр бер йегет.
25. Таң торубән Халид мәйданга керди,
Атың кем? — тиб чарлаб ул Халид сордый.
26. Җаваб бирди Сәкам Халидга рәүван,
Мин Сәкам торурмын, дәлил пәһлеван.
27. Хуран йирликмен, минем Сәкам атым,
Җиһанда чыкмыш минем кывәтем.
28. Гали өчүн килдүм бу йиргә үзүм,
Галимү торурсын? — әйәйем сүзүм.
29. Гали ирмәзмен, үзүм Галинең колый,
Ирүрмен Галинең айакы йулый.
30. Атым Халид ирүр, атам атый Вәлид,
Галини нидәрсен, айа шом пелид?
31. Сәкам әйтүр Халидга — йа, ир ни? —тидиң,
Үзүңни үлүмгә онутубму килдиң.
32. Әйдүр, килдүң имди тукуш кыйлгай,
Бер-беринә хәмлә кыйлдыйлар, кылыч оргай.
33. Йулбарыс, арыслан тик орыш кыйлдыйлар,
Бу икәкү керибән тукуш кыйлдыйлар.
34. Кылыч хәмлә кичди буларның ара,
Орыш эчрә булдый кылычлар парә.
35. Ходайындыйн килди күр казаныйң эшин,
Сәкам кисти, күргил Халидның башыйн.
36. Кылыч берлә ордый Халидни бу Сәкам рәүван,
Шәһид булдый күргил Халид пәһлеван.
37. Кач сәгать кичди, Халид килмәди,
Галинең күңли һәм карар кыйлмадый.
38. Кичә калдый Халид, күргил, нә булдый,
Аһ, дәрига, ул пәһлеван шәһидмү булдый?
39. Гали белди, үлди Халид, килмәди,
Галинең күңли һәм карар кыйлмадый.
40. Күздин акыйбән кыйлмадый йәши,
Терек килмәз ирмеш җөһүдләр берлә кеши.
41. Кем булгай әли йаран ләгыйн пелид,
Тере булдый ул Халид, йа шәһид.
42. Көтдиләр мохтар Халид килмәди,
Гали һәм аны күрүб хәбәрли калмадый.
43. Әйдиләр анлар: бу ничүк булдый,
Халид тик миһри йегет шәһид булдый?
44. Буларда берси мәлик аздыр,
Аның бер нөкәри бар ирди — Миһтәр.
45. Мин барыйб күрәйен, әй, Шир намдар,
Халиднең үчен алайын сад-һәзар.

46. Мифтәр бардый мәйданга тәриктә ишет,
Ач арыслан мингизлик күрәр бер йегет.
47. Ул дәм Мифтәр күрди аный, ачыйг килди,
Катыйг нәгърә оруб мәйданга керди.
48. Мокабил булуб оруш кыйлдыйлар,
Үҗүкмеш арыслан тик тукушдыйлар.
49. Үкүш хәмлә кичди буларның ара,
Оруш эчрә булдый кылычлар парә.
50. Нагяһ килүб кылыч ордый бу Сәкам җуан,
Йәнә кылыч берлә иди бу Мифтәрдин җуан.
51. Кач сәгать кичди, күрди, Мифтәр килмәди
Галинең күңли һәм такый карар кыйлмадый.
52. Гали әйди: әй, йаранлар ни эшләр булдый,
Халид тик Мифтәр һәм шәһидмү булдый?
53. Галинең катында ун йарый бар ирди,
Сәкамга бери бардый, бери килмәди.
54. Андаг әхәд ирди ирәнләрнең иркяри
Такый ул үлтүрди ун ирниң барый.
55. Гали үзи калдый ул мәлик билә,
Икәкү бер-берсигә киңәшләр кыйла.

3. Гали белән мәликнең киңәш итеше

56. Кубуб мәлик Галигә әйтүр: дәстүр бир миңа,
Башыйн тәрик кисәбән киләйен сиңа.
57. Баруб күрәйен мин кем ирмеш аный,
Барыйб алайын мин сахабә каный.
58. Мәйданга керибән тукуш кыйлайын,
Ул ун ирнең үчүн мин алайын.
59. Гали әйди: син тик торгыйл мәлик пәһлеван,
Бер сәгать сабыр кыл, әй, шаһи җиһан.
60. Гали әйтди: сабыр кыл мәлик пәһлеван,
Миңа лайык булгай тукуш кыйлган.

4. Галинең Сәкам белән көрәше

61. Анда кем мин чыксам тукуш кыйлгай,
Сиңа да йук имди оруш кыйлгай.
62. Гали чарлаб әйтүр: айә Канбар һалә!
Алыб кил Делдүлни зөлфокар билә.
63. Алыб килди Канбар Делдүл, зөлфокар,
Галишир атындый тәкъдиргә бакар.
64. Чүн йөрүр ирди мәйданга кериб,
Чарлаб сүзни әйди, Сәкамни күрүб.
65. Гали әйтүр: кем син, айә, пәһлеван,
Кайдан килдүң, айгыл уш имди сән?
66. Әйтте кем: айтгыл айә шири белә
Бу ун ир сахабәни кыйлдуң хажкилә?
67. Ач арыслан мингизлик күрәрмен сини,
Рәхимсез түкмешсен ирәнләр кани.
68. Ул Сәкам бу сүзни ишетти рәүван,
Галигә бирди күб җавабыйн рәүван.

69. Әйттү кем: мин уламын бу, Сәкам атым,
Җиһанда чыкмыш минем кывәтим.
70. Гали өчүн килеб торурмын бу йиргә үзим,
Гали ирсәң әйәйин, сиңа, будур сүзүм:
71. Хуран йирликмен, йәнә Сәкамдур атым,
Мәккәне бозгалы килдүм, әй, шаһым.
72. Уш, имди миңа бер сүзүңне әйт,
Кирәк ирсә җаның — сәламәт кайт.
73. Галинең бу сүзгә ачыкы килеб,
Делдүлни сөрүбән йакыйн ук килеб.
74. Әйдүр кем: әй, монафикъ ләгыйнь,
Мин ул мин, саг-сәламәтмен.
75. Мин ул мин, җаһилләр илин бозгучы,
Мин фәсыйк, ләгыйннең җаныйн өзгүче.
76. Галишир атыйм — ул зөлфокар,
Тәңрим бер, рәсүлем Мөхәммәд мохтар.
77. Ул Сәкам бу сүзни төгәл ишетеб,
Орышмакга тиләди кылычыйн алыб.
78. Сәкам Галигә кылычыйн орубән,
Гали тотдый әлинә калкан алубән
79. Кылычыйн Галигә үз табан баса,
Гали тотдый калканный ул ордый киса.
80. Ики парә кыйлдый калканный Сәкам,
Буның тик кывәтлыйг ирмеш мәхкәм.
81. Булмадый кылычыйн кынкый салыйб,
Билдин кәмәнданый игинә алыйб.
82. Ташладый кәмәнданы Галишир үза,
Галинең билинә чоргашды туша.
83. Бер кывәт кыйлубән тарта алмадый,
Галини атыйндыйн йыка алмадый.
84. Галине үзиндин артукрак күрүб,
Бер сәгать йакыйн ул тәгаҗҗебкә калыйб.
85. Булмадый кылычыйн кыныйга салыйб,
Тотынды Галигә гөрзүсени алыйб.
86. Бу Сәкам өзәйен тиб күтәрди кулын,
Гали тотдый аның йитүбән әлин.
87. Күтәрүб бер кырык аршын һавага аттый,
Йәнә һәм төшермәди әлигә тотдый.
88. Әйүр: бул мөселман, син имди күни,
Белдүңмү, әй, Сәкам, син имди мини?

5. Сәкамнең мөселман булуы һәм Галигә серен сөйләве

89. Хакыйкать мөселман булгыйл куйайын,
Хаҗәтең нә ирсә рәүван мән кыйлайын.
90. Бу Сәкам мөселман булубән рәүван,
Галидән үзигә кылубән аман.
91. Мөселман булубән хакыйкать күргил,
Тәңрем бер, тиди ул, бәнем Мөхәммәд рәсүл.
92. Ишеткел, әй, мөэмин, колак тот сизә,
Ирәнләр эчендә тотмады кинә.

93. Өммәтидүр итүбән Галинең ишин,
Бу Сәкам берлә гыйззәт кыйлмышын.
94. Ирәнләр ишин ирәнләр белүр,
Бигакыйл кешеләр кинә күб кыйлур.
95. Кинәдәр кешени Мөхәммәд миһтар,
Әйтди кем, тәмүгъның эчендә кыйнар.
96. Әй мөэмин, бәс имди кинә тотмагыйл,
Бу кыйссаный ишетеб андаг аңлагыйл.
97. Гакыллылар бу эшни севенәйүбән әйүр,
Йазыкга кеши пошаман булур.
98. Илтүбән күргүзди рәсүлнең йөзүн,
Бу Гали тотубән Сәкамнең кулун.
99. Сад һәзаран дәрди бәхти шад кыйлдыйлар
Сыйпа Шаһ Гали, — тиб барча улдыйлар.
100. Йәнә торуб сөфрә килтүрүб,
Аш-үтмәк билә һәм уңындаку дийүб.
101. Гали әйди: сүзүм бар сиңа, әй Сәкам,
Тоз-үтмәк хакый өчүн гарзың айгыл рәүван.
102. Теләгеңни ирсә бирәйен сиңа,
Хаҗәтеңни ирсә айгыл миңа.
103. Кем бу Сәкам әйди: ишеткел, Гали,
Килдүм ирди мин Мәккә бозгалый.
104. Йәнә бер шәһәрдә бар ирди бер Солтан,
Чириги утыз мең ирди, йиридүр Хуран.
105. Җиһаншаһ табыла чыкмыш атый,
Хәзинәси үкүш ул мал-мөлкәти.
106. Аның бер кызый бар сыйфат кыйлгусыз,
Җәмале, кямале хуш, күреклү йөз.
107. Тиләдүм ушал кызны интизар булуб,
Йалавычлар әйдийән теләдим кулуб.
108. Йалавыч әлиндин маллар издүм үкүш,
Телим килмәгә йибәрдүм алтун-көмүш.
109. Җиһаншаһ йалавыч сүзин ишетеб,
Катына алдырды мине, өндәди әйтеб.
110. Әйди кем: Сәкам, сүзүм бар сиңа,
Ишеткел сүзүмни, колак тот миңа.
111. Син ирүрсен бу Хуранда пәһлеван,
Бу йирдин Мәккәгә баргыйл рәүван!
112. Биш нәрсә әйтәйем, алыб кил миңа,
Милкемнең йарымы һәм кызум сиңа.
113. Мин әйдүм, мин кайу эш нәрсә,
Әйүр тидүм мин, җавабыйн кисә.
114. Мин әйдүм, бу биш нидер йәнә,
Әйтү биргел, тыңла бу дәм йаңа.
115. Әүвәл әйди, Галинең кис башыйн,
Икенчи зөлфокар, өчүнчи Канбар ишин.
116. Түртүнчи эшдүр Делдүл намдар атыйн,
Бишенчи эшдүр Мәликнең гөрзүсин.
117. Җиһаншаһ агыйзыйндыйн бу сүзни ишетеб,
Мәккәгә килдүм тәмами көн-төн ийтеб.
118. Бу биш эшни сөрүб килтүрсәң эшим,
Бирүрмен сиңа никяриң тик кызыйм.

119. Алгалы килән — дөлдүл, зөлфокар,
Галишир әлиндә булдум гөрифтар.
120. Әйүр, кем, бу бишни нитәк кыйлгаймын,
Бу эшниң хәйләсин кемдин белгәймен.
121. Бу Сәкам әйди әшкярә сүзин,
Булуб хәстә күңли, йәшәртиб күзин.
122. Галишир бу сүзни ишетди ирсә,
Фикергә барыйбан, кыйлубан әндишә.

6. Галинең Сәкамне юатуы

123. Гали әйди: Сәкам, кайгырма моңа,
Фаригъ тот күңелни бу эшдин сиңа.
124. Йәнә әйди: бу эшкә мин хәйлә кыйлгаймын,
Бу эшнең хәйләсин мин ук белгәймен.
125. Йәнә әйди Гали: әй, Канбар, килгел һалә,
Алыйб кил Делдүлни зөлфокар белә.
126. Йәнә алыйб килди Канбар зөлфокар,
Ишеткел нә кыйлдый шире җәббар.
127. Ул Канбар Делдүлни зөлфокар билә,
Сәкамга табшуруб алыйб китди һалә.
128. Алыйб бирди Мәликнең гөрзүсин,
Әйди Сәкамга — сүзин һәм арзусин:
129. Илкимни багла тийер, әй, Сәкам җуан,
Башыймный кисеб, моный алыйб бар рәүван.
130. Алыйб бар башымны, шаһыңа биргил,
Теләгең ни ирсә, морадга йиткил.
131. Айгыл, Галини кыйлдыйм мең парә,
Башыный килтүрдүм, белиң әшкярә.
132. Илкимни багла тийер, моны уш кылыч,
Хосумлыйк кыйлмагаймын йәрин анда һич.
133. Бу Сәкам бу сүзни төгәл ишетүб,
Тагаҗҗебкә калдый йаман хәйран булуб.
134. Илкин ташлабән, айакыйна төшүб,
Шаһиншаһ Гали йәнәкүн үкүб.
135. Ихсанәт шаһиншаһы барың ир кеши,
Сәнең дик тугмаган җумард кеши.
136. Йәнә җумард кешиләр малыйный бирүр,
Качан булгай кем дин җанын бирүр.
137. Гали әйди: бар, гидай Сәкам җуан,
Бу башный илтеб йиткер кил рәүван.
138. Күз тотгыйл безни ун көндә кизин,
Җиһаншаһ шаһның бирәйем дадыйн.
139. Йәнә әйди чарлаб: әй, Канбар, намдар,
Алыйб бар буйлә син Делдүл, зөлфокар.
140. Һәр нә эш әйтсә Сәкам, эшин эшлә,
Аның кем, сүзендин чыкмагыйл (һич тә).
141. Сәкамга табшурдый зөлфокар, гөрзүсин,
Ун көндә күз тотгыйл тиди гизин[*].

* «Кыйссаның» дәвамы журналның киләсе санында басылачак.

СҮЗЛЕК:

Айгыл — әйт.
Акыйбән — агып.
Алубән — алып.
Анча — ничек.
Ачыйг килди — ачуы килде.
Әйәйин — әйтәмен.
Әлинә — кулына.
Әхәд — ялгыз.
Әшкярә — ачык.
Багла — бәйлә.
Бигакыйл — акылсыз.
Гарзың — үтенечең.
Гөрифтар — тоткын.
Дадыйн — гаделлеген.
Дәрига — үкенеч.
Дәстүр — рөхсәт.
Җаһилләр — наданнар.
Җуан — яшь.
Изин — рөхсәт.
Икәкү— икесе.
Илкимни — кулларымны.
Илкин ташлабән — кулларын ташлап.
Ирәнләр — яшәүчеләр, яшь
Йәнәкүн — яңагын.
Казаныйң — язмышың.
Кайу — кайсы.
Камугъ — барчасы.
Каумир — ирләр кавеме.
Кач — берничә.
Керибән — кереп.
Кизин — соң.
Кинәдәр — эчкерле.
Кубыр — йөрер.
Күклүк — яшь.
Мәккәгә — Мәккә шәһәренә.
Мәхкәм — таза, нык.
Мингизлик — тиң.
Миһри — дус.
Мокабил — кара-каршы.
Мохтар — ирекле.
Нагяһ — уйламаганда.
Намдар — исемле.
Нәгърә оруб — каты үкереп.
Нигяриңдин — хыялыңдагы.
Нөкәри — сугышчысы.
Оргай — сугып.
Парә — сынды, кисәкләр булды.
Пәһлеван — батыр.
Рәвүан — тиз кит.
Сад-һәзар — каты итеп.
Сордум — сорадым.
Сөфрә — табын.
Тәгаҗҗебкә — исе китеп.
Тәрик — аерып.
Тәриктә — ялгыз.
Терек — исән.
Тигди — җитте.
Тукуш— сугыш.
Ушал — шул.
Үҗүкмеш — үчле.
Үкүш — күп.
Фаригъ — буш.
Фәсыйк — пычрак.
Хаҗилә — изге юл белән.
Хәмлә — һөҗүм.
Хосумлыйк — дошманлык.
Чарлаб — каты кычкырып.
Чаулан илә — шаулап.
Чириги — гаскәре.
Шир намдар — арыслан исемле.
Шире җәббәр — көчле арыслан.
Шири — арыслан кеби.

Өч кулъязма нигезендә тәнкыйди текстны төзүче, аңлатмалар бирүче археограф, филология фәннәре докторы
Марсель Әхмәтҗанов

РЕЗЮМЕ

Среди неизученных памятников татарской литературы средних веков известно поэтическое произведение «Сказание о Сакаме». Литературоведам на сегодняшний день известны четыре рукописных списка сказания: Камкинский, Мало-Кайбицкий, Больше-Менгерский и Усримский. Сюжетом для сказания служила история посылки наемного богатыря Сакама убить вождя мусульман богатыря Али и забрать его военные доспехи. За победу над Али царь неверных обещает Сакаму свою дочь.

В поэме намекается на политику московских князей, которые стали проводить коварную идею разрушения независимости татарских государств. Литературоведом М. И. Ахметзяновым на основе трех списков сказания, объем которых составляет 377 двухстрочных бейтов, составлен критический текст.